СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 28 » февраль 2022 ел** **№ 125**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча район Советы карар бирде:

1.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2.Түбәндәге карарларны үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2012 елның 12 маендагы 134 номерлы карарын;
- «Арча район Советының 2012 елның 17 маендагы 134 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 325 номерлы карарын;
- «Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 325 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Арча район Советының 2017 елның 24 мартындагы 117 номерлы карарын;
- «Арча район Советының 2012 елның 17 маендагы 134 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә җирләрне файдалануга муниципаль җир контроле турында

нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 20 августындагы 264 номерлы карарын (2015 елның 24 апрелендәге 325 номерлы, 2017 елның 24 мартындагы 117 номерлы үзгәрешләр белән).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (parvo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе — И. Г. Нуриев

Арча район Советының
28.02.2022 ел, №125
карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында
Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) җир мөнәсәбәтләре объектларына карата законнарны бозган өчен административ җаваплылык каралган юридик затлар, шәхси эшкуарлар, гражданнар тарафыннан җир законнары таләпләре үтәлешенә муниципаль контроль (алга таба - муниципаль җир контроле) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.
2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле предметы булып түбәндәгеләр тора:

1) юридик затлар, шәхси эшкуарлар, гражданнар (алга таба – контрольдә тотылучы затлар) тарафыннан җирләрдән файдалану өлкәсендә аларны бозган өчен Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында административ җаваплылык каралган Россия Федерациясе законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләр (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәлеше.

2)контрольдә тотылучы затлар тарафыннан рөхсәт документларындагы таләпләрне һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәкле документлар таләпләрен үтәү;

3) контрольдә тотылучы затлар тарафыннан контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарларны үтәү.

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җир мөнәсәбәтләре объектларына карата муниципаль җир контроле Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба - Контроль органы) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Контроль органы исеменнән муниципаль җир контролен түбәндәге вазифаи затлар башкара (алга таба - вәкаләтле вазифаи затлар):

Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе һәм баш белгечләре «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә хокукларга, бурычларга ия һәм җаваплылыкта.

4.Контроль органы муниципаль җир контролен түбәндәгеләрнең үтәлешенә карата башкара:

- җир кишәрлекләрен үзбелдекле биләп алуны булдырмау, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, документлардан башка җир кишәрлекләреннән файдалану, хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру, җирдән файдалану хокукын үзбелдекле башка затка бирү, шулай ук җир кишәрлекләрен

үзбелдекле алмашу турында җир законнары таләпләренә;

- җир кишәрлекләрен арендалау хокукына юридик затлар тарафыннан даими (сроксыз) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштерү яки җир кишәрлекләрен милеккә сатып алу турындагы таләпләргә;

- җир кишәрлекләреннән максатчан билгеләнеше буенча файдалану турында җир законнары таләпләренә;

- күрсәтелгән максатларда авыл хуҗалыгы җитештерүе, торак һәм башка төзелеш өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән мәҗбүри файдалану турында җир законнары таләпләренә («Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон белән авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару яисә авыл хуҗалыгы җитештерүенә бәйле башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җайга салына торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләреннән мәҗбүри файдалануга бәйле таләпләрне үтәүдән тыш);

- җир хуҗалары, җирдән файдаланучылар һәм җирне арендалаучылар тарафыннан граждан һәм җир законнарында билгеләнгән җир кишәрлекләрен үзләштерү срокларына;

- җир кишәрлекләрен арендалаучылар тарафыннан җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларына;

- җирләрне үз вакытында кайтаруга;

- җирләрнең торышы һәм алардан файдалану турында дөрес белешмәләр тапшыруга;

- җирләрдән файдалану мәсьәләләре буенча законнарның башка таләпләрен үтәүгә.

5. Муниципаль җир контроле объектлары булып (алга таба - контроль объектлары) түбәндәгеләр тора:

аларга хокукка бәйсез рәвештә «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан җирләр, җир кишәрлекләре һәм аларның өлешләре;

гражданнар һәм оешмаларның алар кысаларында мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиеш эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмаулары), шул исәптән эшчәнлек, гамәлләр (гамәл кылмаулар) алып баручы гражданнарга һәм оешмаларга карата;

мәҗбүри таләпләр куела торган гражданнар һәм оешмалар эшчәнлеге нәтиҗәләре.

6. Контроль органы муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын исәпкә алуны тәэмин итә.

7. Муниципаль җир контроле түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Җир кодексы;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы;

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 248-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Дәүләт җир күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнарының муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органнар белән үзара

хезмәттәшлеге кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 26 декабрендәге 1515 номерлы карары;

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарының һәм муниципаль контроль органнарының юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары;

Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан файдаланыла торган документларның типлаштырылган формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Җир кодексы;

«Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы;

Арча район Советының 2006 елның 10 февралендәге 34 номерлы карары белән расланган «Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмә»;

әлеге Нигезләмә.

8. Әлеге Нигезләмәдә төп терминнар һәм төшенчәләр «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кулланыла.

## II. Зыян (зарар) килү куркынычы категориясе

9. Муниципаль җир контроле профилактика чараларын һәм контроль чараларны сайлап алуны, аларның эчтәлеген (шул исәптән мәҗбүри таләпләрнең күләме), интенсивлыкны һәм нәтиҗәләрне билгели торган зыян (зарар) килү куркынычы белән идарә итү нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, зыян (зарар) килү куркынычлары белән идарә итү максатларында, контроль объектлары зыян (зарар) килү куркынычының түбәндәге категорияләренең берсенә керә:

урта куркынычлылык;

уртача куркынычлылык;

түбән куркынычлылык.

11. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркынычлылык категориясенә кертү критерийлары әлеге Нигезләмәгә кушымтада бирелә.

12. Контроль объектын куркынычлылык категориясенең берсенә кертү аның характеристикасы расланган куркынычлылык критерийлары белән чагыштыру нигезендә Контроль органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җир кишәрлекләрен куркынычлылык категориясенә керткәндә, Контроль органы тарафыннан шул исәптән түбәндәгеләр кулланыла:

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләр;

Контроль органы вазифаи затларының контроль һәм профилактик чаралар уздыруы турында белешмәләре;

җир төзелеше нәтиҗәсендә алынган дәүләт фондында булган белешмәләр.

13. Тикшерү объекты билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертелмәгән очракта, ул түбән куркынычлылык категориясенә кертелгән дип санала.

14.Контроль органы объектның куркынычлылыкның башка категориясе критерийларына туры килүе турында яисә куркынычлылык критерийлары үзгәрү турында белешмәләр кергән көннән соң биш эш көне эчендә контроль объектының куркынычлылык категориясен үзгәртү турында карар кабул итә.

15. Контроль органы куркынычлылык категориясенә кертелгән җир кишәрлекләре исемлеген (алга таба - җир кишәрлекләре исемлекләрен) алып бара.

Җир кишәрлекләре исемлекләрендә түбәндәге мәгълүмат була:

а) җир кишәрлегенең кадастр номеры яисә, ул булмаганда, җир кишәрлеге урынының адресы;

б) җир кишәрлеге кертелгән куркынычлылык категориясе;

в) җир кишәрлеген куркынычлылык категориясенә кертү турында карар реквизитлары.

16. Куркынычлылык категорияләрен күрсәтеп, җир кишәрлекләрен исемлекләре Контроль органының рәсми сайтында урнаштырыла.

17. Куркынычлылык категориясенә бәйле рәвештә планлы контроль чараларының түбәндәге төрләре һәм ешлыгы билгеләнә:

урта куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектларына карата - 3 елга бер планлы контроль чара;

уртача куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектларына карата - 5 елга бер планлы контроль чара

Түбән куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектларына карата планлы чаралар үткәрелми.

## III. Зыян (зарар) килү куркынычын профилактикалау

18. Профилактик чаралар Контроль органы тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә һәм (яисә) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килергә һәм мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотылучы затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлаштыруны арттыру максатларында гамәлгә ашырыла.

19. Профилактик чаралар ел саен Контроль органы тарафыннан раслана торган закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү куркынычын профилактикалау программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шулай ук күрсәтелгән Программада каралмаган профилактик чаралар да үткәрелергә мөмкин.

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда түбәндәге профилактик чаралар төрләре уздырыла:

мәгълүмат җиткерү;
хокук куллану практикасын гомумиләштерү;
кисәтү игълан итү;
консультация бирү;
профилактик визит.

21. Мәгълүмат җиткерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлешендә каралган белешмәләр һәм мәгълүматларны Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән башкарыла.

Контроль органы күрсәтелгән белешмәләрне актуаль хәлдә тотарга тиеш.

22. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү Контроль органы тарафыннан елга 1 тапкыр уздырыла һәм түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелә:

1) Контроль органы һәм аның вазифаи затлары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнарын куллануга бертөрле алымнарны тәэмин итү;

2) күрсәтелгән хокук бозулар барлыкка килүгә китерә торган мәҗбүри таләпләрне, сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны типик бозуларны ачыклау;

3) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү очракларын анализлау, зыян (зарар) килү куркынычы чыганакларын һәм факторларын ачыклау;

4) мәҗбүри таләпләрне актуальләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

5) дәүләт контроле (күзәтчелек), муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнарына үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр әзерләү.

23. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җир контролен гамәлгә ашыруның хокук куллану практикасын гомумиләштерү Контроль органы тарафыннан үткәрелгән контроль чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турындагы белешмәләрне җыю һәм анализлау юлы белән гамәлгә ашырыла.

Контроль органы хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерли.

Хокук куллану практикасы турындагы доклад Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы күрсәтмәсе белән раслана һәм хисап елыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

24.Контроль органында мәҗбүри таләпләрне бозу әзерләнү яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр кергәндә һәм (яисә) әгәр мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү яисә зыян (зарар) китерү куркынычы тудырган булса, контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү (алга таба - кисәтү) игълан ителә.

Кисәтү Контроль органы җитәкчесе тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләр алынганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча игълан ителә.

25. Кисәтүдә аларның норматив-хокукый актын күздә тоткан тиешле мәҗбүри таләпләргә күрсәтмә, контрольдә тотылучы затның нинди конкрет гамәлләре (гамәл

кылмавы) мәҗбүри таләпләрне бозуга китерүе яки китерә алуы турында мәгълүмат, шулай ук әлеге таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү турында тәкъдим булырга тиеш.

Кисәтү язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә рәсмиләштерелә, кисәтүләрне исәпкә алу журналында теркәлә һәм контрольдә тотылучы зат адресына җибәрелә.

26. Контрольдә тотылучы зат кисәтү алган көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча кисәтүгә карата ризасызлык белдерергә хокуклы.

Ризасызлыкта түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) юридик затның исеме, шәхси эшкуарның, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) салым түләүченең идентификация номеры (юридик зат, шәхси эшкуарның);

3) паспорт яисә шәхесне таныклаучы башка документ сериясе һәм номеры, яшәү урыны адресы, контакт телефоны (гражданнар өчен);

4) контрольдә тотылучы затка карата кисәтү датасы һәм номеры;

5)контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган яисә китерергә мөмкин гамәлләрен (гамәл кылмавын) кисәтүдә күрсәтелгән позицияне нигезләү.

Контроль органына ризасызлыклар контрольдә тотылучы зат тарафыннан кәгазьдә язмача почта аша яки 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда, гади электрон имза яисә көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Контроль органының электрон почтасы адресына яисә кисәтүдә күрсәтелгән башка ысуллар белән җибәрелә.

Контроль органы ризасызлыкны карый, карау нәтиҗәләре буенча контрольдә тотылучы затка ризасызлыкны алган көннән алып 20 эш көне эчендә ризасызлыкка җавап яки ризасызлык белән нигезле килешмәү турында җавап җибәрә.

Ризасызлыкта тәкъдим ителгән дәлилләрне кабул иткән очракта, Контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) элек җибәрелгән кисәтүне юкка чыгара, бу хакта игълан ителгән кисәтүләр журналында билге ясала.

Тиешле нигезләрне күрсәтеп яисә кисәтүне юкка чыгару турында белешмә контрольдә тотылучы зат адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Ризасызлыкларны карау нәтиҗәләре муниципаль җир контролен оештырганда Контроль органы тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чаралар оештыру һәм уздыру һәм гражданнарның, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә бәйле булмаган башка максатларда кулланыла.

27. Контрольдә тотылучы затларның һәм аларның вәкилләренең мөрәҗәгатьләре буенча консультацияләр муниципаль җир контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча Контроль органының вазифаи затлары тарафыннан телефон аша, видео-конференц-элемтә, шәхси кабул итү яки профилактик чара, контроль чара уздыру барышында, шулай ук язма рәвештә бирелә.

Шәхси кабул итү Контроль органы җитәкчесе тарафыннан үткәрелә. Кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турындагы мәгълүмат Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм массакүләм

мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

Контроль органы консультацияләрне исәпкә алу журналын алып бара.

28. Консультация бирү түбәндәге мәсьәләләр буенча телдән яисә язма рәвештә гамәлгә ашырыла:

а) муниципаль җир контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе;

б) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән контроль чараларны гамәлгә ашыру тәртибе;

в) Контроль органы карарларына, аның вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү тәртибе;

г) аларның үтәлешен бәяләү контроль чаралар кысаларында Контроль органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләре булган норматив хокукый актлар (аларның аерым нигезләмәләре) турында мәгълүмат бирү;

29. Язма рәвештә консультация бирү Контроль органының вазифаи заты тарафыннан түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

а) контрольдә тотылучы зат консультация алу мәсьәләләре буенча язма җавап бирү турында язма гариза биргәндә;

б) консультация бирү вакытында куелган сорауларга җавап бирү мөмкин булмаганда;

в) куелган сорауларга җавап мәгълүматны өстәмә соратып алуны таләп иткәндә.

30. Контроль органы контрольдә тотылучы затларга һәм аларның вәкилләренә язма рәвештә телдән консультация бирү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирми.

Контрольдә тотылучы зат «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән срокларда язма җавап бирү турында гарызнамә җибәрергә хокуклы.

31. Контроль органының вазифаи заты консультация бирүне гамәлгә ашырганда, файдалану мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш.

Консультация барышында түбәндәгеләр бирелә алмый:

Контроль органы вазифаи затларының, контроль чараның башка катнашучыларының конкрет чарасын, карарларын һәм (яисә) гамәлләрен бәяләүне үз эченә алган мәгълүмат;

экспертиза, сынаулар кысаларында үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре.

Контроль органының вазифаи затына мәгълүм булган мәгълүмат мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча контрольдә тотылучы затны бәяләү максатларында файдаланыла алмый.

32. Контроль органына контрольдә тотылучы затлардан һәм аларның вәкилләреннән 5 һәм аннан күбрәк бер типтагы мөрәҗәгать кергән очракта, консультация Контроль органының вәкаләтле вазифаи заты кул куйган язма аңлатмалар рәвешендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бирелә.

33. Профилактик визит контрольдә тотылучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча кисәтү әңгәмәсе рәвешендә яки видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән уздырыла.

Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы зат үз эшчәнлегенә яки үз карамагындагы контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр,

аларның куркынычлылык критерийларына туры килүе, куркынычлылык категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары һәм нигезләр турында, шулай ук контроль объектына карата, аларны нинди куркынычлылык категориясенә кертүдән чыгып, контроль чараларның төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында мәгълүмат бирә.

Профилактик визит үткәргәндә контроль объектларының закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килүгә турыдан-туры куркыныч туу яки мондый зыян (зарар) килү ачыкланса, Контроль органының вазифаи заты үткәрелгән профилактик визит турында хисап рәвешендә контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен бу хакта кичекмәстән Контроль органы җитәкчесенә хәбәр итә.

34. Профилактик визит җир законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыруга керешә торган контрольдә тотылучы затларга карата мондый эшчәнлек башланган мизгелдән бер ел эчендә уздырыла.

Контроль органы контрольдә тотылучы затка мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында аны үткәрү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

Мәҗбүри профилактик визит уздыру турында хәбәрнамә язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә төзелә һәм түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

1) хәбәрнамәне төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) Контроль органы исеме;

3) контрольдә тотылучы затның тулы исеме;

4) вәкаләтле вазифаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

5) мәҗбүри профилактик визит датасы, вакыты һәм урыны;

6) вәкаләтле вазифаи зат имзасы.

Мәҗбүри профилактик визитны уздыру турында хәбәрнамә контрольдә тотылучы зат адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Контрольдә тотылучы зат мәҗбүри профилактик визит үткәрүдән баш тартырга хокуклы, бу хакта ул аны уздыру датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, мәҗбүри профилактик визит уздыру турында хәбәрнамә юллаган Контроль органына хәбәр итәргә тиеш.

Мәҗбүри профилактик визит уздыру срогы Контроль органы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә һәм бер эш көненнән артмаска тиеш.

## IV. Контроль чаралар

35. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда Контроль органы түбәндәге чаралар кысаларында контроль чаралар һәм контроль гамәлләр төрләрен уздыра ала:

а) инспекция визиты (мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә тотылучы зат яки контроль объекты (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан урынында булырга тиешле документларны карау, сораштыру, теркәү юлы белән (тикшерү, язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшерү);

б) рейд тикшерүе (тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә тотыла торган зат яки контроль объекты (аның

филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашкан урында, инструменталь тикшерү, экспертиза ясау юлы белән;

в) документар тикшерү (язма аңлатмалар алу, документлар соратып алу, экспертиза уздыру юлы белән);

г)күчмә тикшерү (тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документларны теркәү, инструменталь тикшерү юлы белән);

д) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (җирләр, җир кишәрлекләре һәм аларның өлешләрен, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кирә торган белешмәләрне, анализлау ярдәмендә, муниципаль хезмәт күрсәтүләрне һәм функцияләрне башкару кысаларында бирелә торган, шулай ук дәүләт, муниципаль һәм ведомство мәгълүмат системаларында булган күрсәткечләр);

е) күчмә тикшерү (тикшерү, инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып).

Планлаштырылган контроль чараларының төрләре Контроль органы тарафыннан куркынычлылык категориясеннән чыгып сайлана.

Уртача куркынычлылык категориясенә керә торган объектларга карата түбәндәгеләр уздырыла: тикшерү (тикшерү, сораштыру, мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә тотылучы зат  (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яки контроль объектыннан язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшерү урыннарында булырга тиешле документлар соратып алу юлы белән);

рейд тикшерүе (тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә тотылучы зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашкан урында, инструменталь тикшерү, экспертиза ясау юлы белән);

күчмә тикшерү (тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар солратып алу, инструменталь тикшерү юлы белән)

Уртача куркынычлылык категориясенә караган объектларга карата документар тикшерү документар тикшерү (язмача аңлатмалар, документларны таләп итү юлы белән), мәҗбүри таләпләрнең (контроль объектлары турында булган мәгълүматларны, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кергән мәгълүматларны җыю, анализлау юлы белән) үтәлешен күзәтү, шулай ук "Интернет" челтәреннән, башка иҗтимагый мәгълүматлардан торган дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларында булган мәгълүматлар.

Планнан тыш контроль чаралар төрләре әлеге Нигезләмәнең 41 пунктында билгеләнгән контроль чараны уздыру нигезләренә карап билгеләнә.

36. Контроль чаралар барышында түбәндәге контроль гамәлләр башкарыла:

а) карау (осмотр);

б) сораштыру;

в) язма аңлатмалар алу;

г) документлар соратып алу;

д) инструменталь тикшерү;

е) экспертиза.

Контроль гамәлләрне уздыру тәртибе 248-ФЗ номерлы Федераль законның 14 бүлеге нигезендә җайга салына.

37. Контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлек түбәндәге контроль

чаралар уздырганда гамәлгә ашырыла:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документар тикшерү;

г) күчмә тикшерү.

38.Контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлек итмичә түбәндәге контроль чаралар уздырыла:

а) контроль таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

б) күчмә тикшерү.

39. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге планлы контроль чаралар үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документар тикшерү;

г) күчмә тикшерү.

40. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге планнан тыш контроль чаралар үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документар тикшерү;

г) күчмә тикшерү;

д) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

е) күчмә тикшерү (обследование)

41.Контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлектә уздырыла торган контроль чараларны үткәрү өчен нигезләр:

а) Контроль органында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү яки зыян (зарар) килү куркынычы туу турында яисә объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары раслаган параметрларга туры килү-килмәү ачыклану яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе ачыклану турында белешмәләр булу;

б) контроль чаралар уздыру планына кертелгән контроль чараларны үткәрү сроклары якынлашу;

в) Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контрольдә тотылучы затларга карата контроль чаралар уздыру турындагы йөкләмәсе;

г) законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча үтәү кысаларында контроль чара уздыру турында прокурор таләбе;

42. Контроль чаралар, тикшереп тору органының вәкаләтле вазифаи затлары биремнәре нигезендә, Контроль органының эш планнарындагы, шул исәптән 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда, вәкаләтле вазифаи затлар тарафыннан башкарыла.

43. Контроль чара, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүдән һәм күчмә тикшерүдән тыш, аны формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре белән билгеләнгән контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына керткәннән соң башланырга мөмкин (Реестр операторы теркәгән контроль (күзәтчелек) чараларның

бердәм реестрының эшкә яраксызлыгы очракларыннан тыш).

44. Контрольдә тотылучы зат яисә аның вәкиле булырга тиешле контроль чара яки контроль гамәлләр кылганда контрольдә тотылучы зат яки аның вәкиле катнашырга тиеш, контрольдә тотылучы зат белән үзара бәйләнешне таләп итми торган контроль чара яки контроль гамәлләр кылудан тыш.

Контрольдә тотылучы зат яисә аның вәкиле булмаган очракта, контрольдә тотылучы зат тарафыннан контроль чара яки контроль гамәлләр кылганда катнашу мөмкинлеге булмау турында Контроль органына мәгълүмат кергәндә, контрольдә тотылучы затка контроль чара уздыру турында тиешенчә хәбәр ителгән очракта, контроль чараны үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү контрольдә тотылучы заттан башка гына башкарылырга мөмкин булганда, контроль гамәлләр кылына.

45.Шәхси эшкуар, контрольдә тотылучы зат булган граждан Контроль органына контроль чараны үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмау турында мәгълүматны түбәндәге очракларда тапшырырга хокуклы:

1) медицина учреждениесендә стационар дәвалануда булу;

2) Россия Федерациясеннән читтә булу;

3) административ кулга алыну;

4) җинаять кылуда шикләнелүчегә карата чикләү чарасы сайлану: читкә китмәү һәм үз-үзен тиешенчә тоту турында язма, билгеле бер гамәлләрне тыю, сак астына алыну, йорт аресты рәвешендә;

5) контроль (күзәтчелек) чарасын үткәргәндә зат катнаша алмаслык форс-мажор шартлар булган очракта (хәрби хәрәкәтләр, һәлакәт, стихияле бәла-каза, эре авария, эпидемия һәм башка гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килү.

Контроль чара уздырганда катнашу мөмкинлеге булмау турында мәгълүмат кергән очракта, аны үткәрү Контроль органы тарафыннан шәхси эшкуар, гражданның әлеге мөрәҗәгатенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле срокка күчерелә.

46. Форс-мажор хәлләр килеп чыкканда, контрольдә тотылучы зат Контроль органы адресына түбәндәгеләрне үз эченә алган мәгълүмат җибәрә:

а) форс-мажор шартлары һәм аларның дәвамлылыгы тасвирламасы;

б) барлыкка килгән форс-мажор шартлары һәм контроль (күзәтчелек) чарасын үткәргәндә тоткарлык булу-булмау арасында сәбәп-тикшерү бәйләнеше турында белешмәләр;

в) контроль (күзәтчелек) чарасын үткәргәндә катнашуга комачаулаучы хәлләрне бетерү өчен кирәкле срокны күрсәтү.

Күрсәтелгән мәгълүмат биргәндә контроль чараны үткәрү вакыты Контроль органы тарафыннан шәхси эшкуарның, гражданның әлеге мөрәҗәгатенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

47. Муниципаль җир контролен оештырганда һәм гамәлгә ашырганда контроль орган бу документлар һәм (яки) белешмәләр ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, шул исәптән электрон формада булган башка органнардан документлар һәм (яки) белешмәләр ала.

Күрсәтелгән документлар һәм (яки) белешмәләр исемлеге, аларны тапшыру тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 6 мартындагы

338 номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында» карары белән расланган контроль (күзәтчелек) органнары яисә әлеге органнарга караган бүтән оешмалардан алынган мәгълүматлардан һәм (яки) дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контроль төрләрен оештырганда һәм гамәлгә ашырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган белешмәләр, документларны тапшыру кагыйдәләре белән билгеләнә.

48. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга һәм гражданнарга карата планлы контроль чаралар, чираттагы календарь елына планлы тикшерү (күзәтчелек) чаралары үткәрү планын формалаштыру, аны прокуратура органнары белән килештерү, ел дәвамында аңа контроль (күзәтчелек) чараларын кертү һәм төшереп калдыру Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чираттагы календарь елына планлы тикшерү (күзәтчелек) чаралары үткәрү планын формалаштыру, аны прокуратура органнары белән килештерү, ел дәвамында аңа контроль (күзәтчелек) чараларын кертү һәм төшереп калдыру тәртибе турында» 2020 елның 31 декабрендәге 2428 номерлы карары белән расланган кагыйдәләре нигезендә үткәрелә.

49. Контроль органының вазифаи затлары һәм контроль гамәлләрне башкаруга җәлеп ителә торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен контроль чараны уздыруга вәкаләтле вазифаи затлар тарафыннан үткәрелгән фотосурәт һәм/яисә аудио һәм видеоязма, геодезик һәм картометрик үлчәүләр кулланылырга мөмкин.

Фотосурәт, аудио- һәм видеога яздыру кирәклеге, контроль чараларны гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәүнең башка ысуллары турындагы карар Контроль органының вазифаи заты тарафыннан мөстәкыйль кабул ителә.

Фотосурәт, аудио һәм видеоязмалар контрольдә тотылучы затка мәҗбүри хәбәр ителеп башкарыла.

50. Фотосурәт ярдәмендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны теркәү кимендә ике сурәт ярдәмендә башкарыла. Фотосурәт нокталары һәм юнәлешләре аңа карата контроль чара үткәрелә торган җир мөнәсәбәтләре объекты схемасында билгеләнә. Контроль чаралар уздырганда мәҗбүри таләпләрне үтәүнең (бозуның) дәлилләрен теркәү өчен кулланыла торган фотога төшерү һәм видеоязма тиешле дәрәҗәдә яктылыкта үткәрелергә тиеш.

Контроль чараны уздыру барышы аудио һәм видеоязма башкару датасы, урыны, вакыты һәм тәмамлануы турында хәбәр итеп, өзлексез рәвештә башкарыла. Яздыру барышында мәҗбүри таләпләрне бозуның урыны һәм характеры җентекләп теркәлә һәм күрсәтелә.

51. Фотосурәт, аудио һәм видеоязма, геодезик һәм картометрик үлчәүләр һәм әлеге максатлар өчен файдаланылган техник чаралар турында мәгълүмат контроль чара нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта һәм контроль чара кысаларында үткәрелә торган контроль гамәл нәтиҗәләре буенча төзелә торган беркетмәдә чагыла.

Фотосурәт һәм аудио һәм видеоязма мәҗбүри таләпләрне бозуларның дәлилләрен теркәү өчен дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Фотосурәтләр, аудио һәм видеоязмалар үткәрү нәтиҗәләре контроль чара

актына кушымта булып тора.

Контроль чаралар үткәрү барышында Контроль органы вазифаи затлары тарафыннан башкарыла торган геодезик үлчәүләр (билгеләүләр) һәм (яисә) картографик үлчәүләр инструменталь үлчәүләр үткәрү юлы белән башкарыла.

52. Инспекция визиты контрольдә тотылучы затның яки контроль объектының (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу (эшчәнлеген гамәлгә ашыру) урыны буенча конкрет контрольдә тотылучы зат һәм (яисә) хуҗасы (кулланучы) белән үзара хезмәттәшлектә уздырыла.

Инспекция визиты контрольдә тотылучы затка һәм контроль объекты милекчесенә алдан хәбәр итмичә уздырыла.

Эшчәнлекне гамәлгә ашыруның бер урынында яки бер контроль объектында инспекция визитын үткәрү бер эш көненнән артып китә алмый.

Контрольдә тотылучы затлар яисә аларның вәкилләре Контроль органы вазифаи затының биналарга, корылмаларга каршылыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

53. Рейд тикшерүе алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында контрольдә тотуны, файдалануны яисә контроль объекты белән идарә итүне гамәлгә ашыручы теләсә кайсы контрольдә тотылучы затка карата үткәрелә.

Рейд тикшерүен үткәрү контроль чараны үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар, белгечләр катнашында (кирәк булганда) уртак (ведомствоара) контроль чарасы рәвешендә контроль чара уздыру турындагы карар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Рейд тикшерүен үткәрү срогы ун эш көненнән артмаска тиеш. Рейд тикшерүе чорында бер контрольдә тотылучы зат белән хезмәттәшлек итү срогы бер эш көненнән артып китә алмый.

Рейд тикшерүен уздырганда Контроль органының вазифаи затлары контроль объектындагы затлар белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

Контрольдә тотылучы затлар рейд тикшерүе барышында вәкаләтле вазифаи затларның контроль объектларына тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Рейд тикшерүе нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта, Контроль органының җаваплы вазифаи заты һәр контрольдә тотыла торган затка карата урында акт төзи, шул ук вакытта барлык контроль нәтиҗәләренә карата мәгълүмат булган аерым акт рәсмиләштерелми.

54. Документар тикшерү Контроль органының урнашу урыны буенча үткәрелә, аның предметы-контрольдә тотылучы затлар документларында оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган белешмәләр, шулай ук контрольдә тотылучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) урнашкан (эшчәнлек алып барган) урыны буенча аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган һәм Контроль органы карарларын һәм мәҗбүри таләпләрен үтәү белән бәйле документлар.

Документар тикшерү барышында контрольдә тотылучы затларның Контроль органы карамагында булган документлары, алдагы тикшерү чаралары нәтиҗәләре, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материаллары һәм муниципаль җир контроленең әлеге контрольдә тотылучы затларга карата

башкарылган эш нәтиҗәләре турында башка документлар карала.

Контроль органы карамагында булган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудырса яки әлеге белешмәләр контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, Контроль органы контрольдә тотылучы зат адресына документлар тикшерү барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру кирәклеге турында таләп җибәрә.

Контрольдә тотылучы зат күрсәтелгән документларны таләп алынган көннән алып ун эш көне эчендә Контроль органына тапшырырга тиеш.

55. Документар тикшерү барышында контрольдә тотылучы зат тапшырган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар яки әлеге документлардагы белешмәләрнең Контроль органында булган документлардагы һәм (яисә) муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве ачыкланса, контрольдә тотылучы затка ун эш көне эчендә тиешле аңлатмалар бирү кирәклеге турында таләп җибәрелә.

Контрольдә тотылучы зат, таләп ителә торган аңлатмалардан тыш, өстәмә рәвештә Контроль органына элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

Документар тикшерү уздырганда Контроль органы тарафыннан документар тикшерү предметына карамый торган белешмәләр һәм документлар, шулай ук контрольдә тотучы заттан башка органнардан алынырга мөмкин булган белешмәләр һәм документлар таләп ителми.

56. Документар тикшерү үткәрү срогы ун эш көненнән артмаска тиеш.

Күрсәтелгән срокка Контроль органы тарафыннан контрольдә тотылучы затка җибәрелгән вакыттан алып документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны Контроль органына тапшыру турында таләп җибәрү вакыты, шулай ук контрольдә тотылучы зат тарафыннан бирелгән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыклану яисә әлеге документлардагы белешмәләрнең Контроль органында булган һәм (яки) муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда алынган документлардагы белешмәләргә туры килмәве турында Контроль органының мәгълүмат җибәрү вакыты һәм контрольдә тотылучы затка аңлатмалар бирү кирәклеге турында таләп җибәрелү вакыты керми.

57. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килештермичә үткәрелә.

58. Күчмә тикшерү контроль объектларына ия булган һәм (яисә) алардан файдаланучы конкрет контрольдә тотылучы зат белән хезмәттәшлек итү юлы белән мондый затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләү, шулай ук Контроль органы карарларының үтәлешен бәяләү максатларында уздырыла.

Күчмә тикшерү контрольдә тотылучы зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яки контроль объекты урнашкан (эшчәнлеген гамәлгә ашырган) урын буенча уздырыла.

59. Күчмә тикшерү түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта уздырыла:

1) Контроль органы карамагында яисә ул соратып алган документларда һәм контрольдә тотылучы затның аңлатмаларында булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

2) контрольдә тотылучы затның һәм (яки) аның карамагындагы һәм (яки)

кулланылучы контроль объектларының әлеге Нигезләмәнең 58 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән урынга чыкмыйча гына эшчәнлегенең, гамәлләренең (гамәл кылмавының) һәм контроль чараларының башка төре кысаларында каралган кирәкле контроль гамәлләрнең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү.

60. Планнан тыш күчмә тикшерү 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 1 өлешенең 3 - 6 пунктларына, 57 статьясындагы 3 өлешенә һәм 12 өлешенә туры китереп, прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин.

Күчмә тикшерү үткәрү турында контрольдә тотылучы затка, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, күчмә тикшерүне үткәрү турында карар күчермәсен ул башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә җибәрү юлы белән хәбәр ителә.

61. Күчмә тикшерү үткәрү срогы ун эш көненнән артмаска тиеш.

Күчмә тикшерү барышында кече эшкуарлыкның бер субъектына карата үзара хезмәттәшлекнең гомуми срогы кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

62. Күчмә тикшерү контрольдә тотылучы затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында уздырыла.

Күчмә тикшерү оешманың (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашкан (эшчәнлек алып барган) урыны, граждан эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны, контроль объектының урнашкан урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлек итү рөхсәт ителми.

Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган карарлар кабул ителә алмый.

Бер объектка (бер-берсенә турыдан-туры якын урнашкан берничә объектка) күчмә тикшерү үткәрү срогы бер эш көненнән артып китә алмый.

63. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү(иминлек мониторингы) Контроль органында булган контроль объектлары турында, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кергән мәгълүматларны, дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларында булган мәгълүматларны, «Интернет» челтәреннән, башка һәркем өчен мөмкин булган башка мәгълүматларны, шулай ук фотога һәм кинога төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автоматик режимында эшләүче техник чараларын кулланып алынган белешмәләрне җыю, анализлаудан гыйбарәт.

Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәткәндә(иминлек мониторингы), контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләр белән билгеләнмәгән бурычлар йөкләнә алмый.

Мәҗбүри таләпләрне үтәүне күзәтү (иминлек мониторингы) барышында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү яисә зыян (зарар) килү куркынычы туу фактлары ачыклану, мәҗбүри таләпләрне бозулар, мәҗбүри таләпләрне бозу әзерләнү һәм мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр кергән очракта, Контроль органы тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителергә мөмкин:

1) 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясы нигезендә планнан тыш контроль чара уздыру турында карар;

2) кисәтү игълан итү турында карар.

64. Әлеге Нигезләмәнең 37 пунктында күрсәтелгән контроль чараларны үткәрү тәмамлангач, конкрет контроль чара өчен Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә контроль чара акты төзелә.

Ачыкланган хокук бозулар бетерелгән очракта, актта контроль чара үткәрү тәмамланганчы аны бетерү факты күрсәтелә.

Мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләре булган документлар, башка материаллар актка беркетелергә тиеш. Контроль чара уздырганда тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлә.

Актны рәсмиләштерү мондый чараны уздыру тәмамланган көнне контроль чараны уздыру урынында башкарыла.

Дәүләт, коммерция, хезмәт яки закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итүче контроль чара нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

Прокуратура органнары тарафыннан килештерелгән контроль чара акты контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестры ярдәмендә прокуратура органнарына җибәрелә.

65. Контроль чаралар турында мәгълүмат контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында урнаштырыла.

66. Контрольдә тотылучы зат яисә аның вәкиле акт эчтәлеге белән контроль чараны уздыру урынында таныша.

Документар тикшерү яисә контроль чара контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлектән башка үткәрелгән очракта, шулай ук экспертиза үткәрелгән урында контроль чара нәтиҗәләре буенча акт төзү мөмкин булмаган очракта, Контроль органы актны контрольдә тотылучы затка 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Контрольдә тотылучы зат акт әзерләнгән ысул белән актка кул куя. Контрольдә тотылучы зат яисә аның вәкиле тарафыннан контроль чарасын уздыру йомгаклары буенча актка имза кую кире кагылса яисә мөмкин булмаса, актта тиешле тамга ясала.

Контроль чара актында бәян ителгән фактлар һәм нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, контрольдә тотылучы зат әлеге Нигезләмәнең V бүлегендә каралган тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

67. Тикшерү чарасын үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланмаган очракта, бу хакта белешмәләр контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына кертелә.

Контроль органының вазифаи заты мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча тәкъдимнәр бирергә, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар үткәрергә хокуклы.

Контроль чара үткәргәндә контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, Россия Федерациясе законнарында

каралган вәкаләтләр чикләрендә Контроль органы түбәндәгеләргә бурычлы:

1) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килүне булдырмау яисә аны туктату буенча законнарда каралган чараларны кичекмәстән кабул итәргә һәм гражданнарны, оешмаларны закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү куркынычы булу турында һәм, әгәр контроль чараны үткәргәндә гражданның, контроль объектына ия булган һәм (яисә) аннан файдаланучы оешманың эшчәнлеге закон тарафыннан саклана торган зыян килгәндә, аны булдырмау ысуллары турында мәгълүмат житкерергә;

2) Россия Федерациясе законнарында административ яисә җинаять җаваплылыгы каралган җир законнарын бозулар ачыклаганда, контроль чара актының күчермәсен дәүләт җир күзәтчелеге органына җибәрергә;

3) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү мөмкинлеген булдырмау, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү, бозуларны кисәтү чараларын күрергә;

4) мәҗбүри таләпләрне үтәү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) килү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар уздыру буенча тәкъдимнәр бирү турындагы мәсьәләне карарга.

## V. Контроль органы карарларына, Контроль органы вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирү

68. Контроль органы карарларына, аның муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлеге билгеләгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

69. Контроль органы карарларына, аның вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр шикаять бирелергә мөмкин, эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан судка шикаять бирү очракларыннан тыш.

70. Законлы хокуклары һәм мәнфәгатьләре турыдан-туры муниципаль җир контроле кысаларында бозылган дип санаучы контрольдә тотылучы затлар түбәндәгеләргә карата судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар уздыру турындагы карарлар;

б) контроль чаралар актлары;

в) контроль чаралар кысаларында Контроль органы вазифаи затларының гамәлләре (гамәл кылмаулары).

71.Шикаять контрольдә тотылучы зат тарафыннан Контроль органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып, электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять граждан тарафыннан бирелгәндә, ул аның гади электрон имзасы яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланырга тиеш.

Шикаять оешма тарафыннан бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаять, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланмыйча, дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган

башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, контрольдә тотылучы зат тарафыннан кәгазьдә тапшырыла.

72. Контроль органы карарына, аның вазифаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Контроль органы җитәкчесе тарафыннан карала.

Контроль органы җитәкчесенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан карала.

73. Контроль органы карарына, аның вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять контрольдә тотылучы зат үз хокукларын бозу турында белгән яисә белергә тиеш булган көннән соң утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү срогы җитди сәбәп аркасында узып киткән очракта, шикаять биргән затның үтенечнамәсе буенча әлеге срок Контроль органы тарафыннан торгызылырга мөмкин.

Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне шул ук нигезләр буенча кабат җибәрү рөхсәт ителми.

Шикаятьтә Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында үтенеч булырга мөмкин.

74. Контроль органы шикаятьне теркәгән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында;

Шикаять белдерелә торган карарның үтәлешен туктатып тору турында үтенечнамә карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

75. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган Контроль органы вазифаи затының исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләр, яки мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың ышанычнамәсе буенча шикаять биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), урнашкан урыны турында белешмәләр, яисә шикаятьне карау вакытында үзара бәйләнешне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча кабул ителгән карарны алу ысулы;

3)Контроль органының һәм (яисә) аның вазифаи затының алар шикаять биргән контрольдә торучы затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган дәгъвалана торган карары турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең Контроль органы карары һәм (яисә) вазифаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән нигезләре һәм дәлилләре. Гариза бирүче әлеге дәлилләрне раслый торган документларны яки аларның

күчермәләрен (булган очракта) тапшыра ала;

5) шикаять биргән затның таләпләре;

6) аңа карата шикаять бирелә торган контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында контроль чараны исәпкә алу номеры, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса.

Шикаятьтә Контроль органы вазифаи затларының, аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаган, цензурасыз яисә мыскыллы сүзләр булырга тиеш түгел.

Шикаятьне контрольдә тотылучы зат, аның тарафыннан тиешле хокук бирелгән вәкаләтле вәкиле биргән очракта, шикаять «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә бирелергә мөмкин.

Шикаятькә Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилнең, аның иҗтимагый вәкиленең шикаятькә кагылышлы карашы кушылырга мөмкин.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, аның иҗтимагый вәкиле карашына җавап Контроль органы тарафыннан шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

76. Контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазифаи зат) түбәндәге очракларда шикаятьне алган вакыттан алып биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 73 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы тәмамланганнан соң бирелгән һәм аны торгызу турында яисә шикаять бирүнең билгеләнгән срогын торгызу турында үтенечнамә булмау;

2) шикаять бирү вакытын торгызу турында үтенечнамәнең канәгатьләндерүдән баш тартылган булуы;

3) аны биргән контрольдә тотылучы заттан шикаять буенча карар кабул ителгәнчегә кадәр шикаятьне кире алу турында гариза кергән булу;

4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары булу;

5) Контроль органына элегрәк шул ук контрольдә тотылучы заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелгән булу;

6) шикаятьтә Контроль органы вазифаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаган, цензурасыз яисә мыскыллаучы сүзләр булу;

7) яңа дәлилләр яисә хәлләр китерелмәсә, әлеге контрольдә тотылучы затның шул ук предмет буенча шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген булдырмый торган шикаятьне караудан элегрәк баш тартылган булу;

8) шикаять тиешле булмаган Контроль органына бирелү;

9) Россия Федерациясе законнары нигезендә Контроль органы карарларына шикаять белдерү суд тәртибендә генә каралу.

Әлеге пунктның 3 - 8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, аның вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

77. Контроль органының шикаятьне карауга вәкаләтле вәкиле шикаятьне

караганда контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирүнең өстәмә системасыннан файдалана, моңа шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклар керми.

Контроль органы судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләр тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау, Россия Федерациясенең закон тарафыннан саклана торган башка сер турындагы законнары таләпләрен үтәгән килеш, контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге системасыннан файдаланмыйча, Контроль органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

78. Шикаять Контроль органы тарафыннан аны теркәгән көннән алып егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аерым очракларда, күрсәтелгән срок орган тарафыннан озынайтылырга мөмкин, әмма ул егерме эш көненнән дә артык була алмый.

79. Контроль органы шикаять биргән контрольдә тотылучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорарга хокуклы.

Контрольдә тотылучы зат күрсәтелгән мәгълүматны һәм документларны сорату җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы дәвамында шикаять предметына кирә торган өстәмә мәгълүмат һәм документлар тапшыру турындагы запрос җибәргәннән соң, аларны Контроль органы алган мизгелгә кадәр туктатылып тора, ләкин запрос җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артмаска тиеш.

Контрольдә тотылучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар алынмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

Шикаять биргән контрольдә тотылучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынган оешмалар карамагында булган мәгълүматны һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнчегә кадәр үз чиратында шикаять предметына караган өстәмә материалларны тапшырырга хокуклы.

80. Вазифаи затның шикаять белдерелә торган карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавына) карата кабул ителгән карарның законлылыгын һәм нигезлелеген һәм (яисә) гамәл кылуын (гамәл кылмавын) раслау бурычы Контроль органына йөкләнә.

81. Шикаятьне карау йомгаклары буенча Контроль органы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләнмичә калдыра;

2) Контроль органы карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль органы карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органы вазифаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм асылы буенча, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында карар чыгара.

82. Кабул ителгән карарны нигезли торган Контроль орган карары, аны үтәү срогы һәм тәртибе ул кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең

бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында контрольдә тотылучы затның шәхси кабинетында урнаштырыла.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау йомгаклары буенча контроль орган карары, дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка сер турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәгән хәлдә, контрольдә тотылучы затка кәгазь чыганакта җибәрелә.

«Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге территориясендә
җир контроле турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда җир кишәрлекләренең хокук ияләре булган гражданнар, юридик затлар һәм (яисә) шәхси эшкуарлар файдалана торган җирләрне куркынычлылык категориясенә кертү критерийләре**

1. Урта куркынычлылык категориясенә түбәндәгеләр керә:

а) җитештерү һәм куллану калдыкларын күмү һәм урнаштыру, зиратлар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре;

б) гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосасы чикләрендә урнашкан яисә аның чигенә тоташкан җир кишәрлекләре.

2. Уртача куркынычлылык категориясенә түбәндәге җир кишәрлекләре керә:

а) торак пунктларның җирләре категориясенә керүчеләр һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә, урман фонды җирләре, җирләр, махсус саклана торган территорияләр һәм объектлар, запас җирләр белән чиктәш җир кишәрлекләре;

б) сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, куркынычсызлык һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр, автомобиль юллары, тимер юллар, торба үткәргеч транспорт, электр линияләре һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр белән чиктәш җирләрдән тыш;

в) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә керә торган һәм торак пунктлар җирләре категориясенә караган җирләр һәм (яки) җир кишәрлекләре белән чиктәш җирләр.

3. Түбән куркынычлылык категориясенә урта яисә уртача куркынычлылык категориясенә кертелмәгән барлык җир кишәрлекләре керә.

«Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге территориясендә
җир контроле турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозуның куркынычлылык индикаторлары исемлеге**

1. Контроль чара үткәрү нәтиҗәсендә билгеләнгән җир кишәрлегенең контрольдә тотылучы зат тарафыннан файдаланыла торган мәйданының җир кишәрлегенә хокук билгели торган күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында булган җир кишәрлеге мәйданына туры килмәве.

2. Контрольдә тотылучы зат тарафыннан җир кишәрлегеннән файдалану турында белешмәләр җир кишәрлегенә хокук билгели торган Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында булган җир кишәрлегеннән фактта файдалану максатында кулланылмавы.

3. Җир кишәрлеген бирү вакытыннан алып өч елдан артык вакыт узу яки җир кишәрлеген арендалау килешүендә күрсәтелгән җир кишәрлеген үзләштерү срогы тәмамлану, ә җир кишәрлегендә характерлы үзгәрешләр күзәтелмәү (капиталь төзелеш объекты булмау, төзелеш эшләре алып бару һәм җир кишәрлегеннән файдалану буенча башка гамәлләр һәм рөхсәт ителгән файдалану һәм бирү шартлары нигезендә башка гамәлләр булмау).

4. Җир кишәрлекләреннән файдалану өчен нигез булып торган документларны рәсмиләштерүгә карата мәҗбүри таләпләр үтәлмәү.

«Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге территориясендә
җир контроле турында Нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләре һәм индикатив күрсәткечләре**[1]

| Төп күрсәткечләр | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|
| Ачыкланган җир законнарын бозулардан бетерелгән бозулар проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елга планлы контроль чаралар уздыру планын үтәү проценты | 100% |
| Контроль чаралар уздырганда муниципаль контроль органы һәм (яисә) аның вазифаи затының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата нигезле шикаятьләр проценты | 0% |
| Контроль чараларның гамәлдән чыгарылган нәтиҗәләре процентлары | 0% |
| Тиешле административ йогынты ясау чаралары кабул ителмәгән нәтиҗәле контроль чаралар проценты | 5% |
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында кертелгән суд карарлары проценты | 95% |
| Административ хокук бозулар турында эшләр буенча муниципаль контроль органы чыгарган карарларның гомуми санынннан суд тәртибендә юкка чыгарылган карарларның проценты | 0% |

| **1.** | **Уздырылган чараларның параметрларын характерлый торган хосусый күрсәткечләр** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.1. | Планлаштырылган (рейд) биремнәр | Врз = (РЗф / РЗп) | Врз - план (рейд) биремнәре | 100 % | Расланган план (рейд) биремнәре |

[1] *Контроль төренең күрсәтелгән төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, индикатив күрсәткечләр якынча характерга ия.*

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | (караулар) үтәлеше | x 100 | (караулар) үтәлеше<br>РЗф - план (рейд) биремнәре (караулар) саны (бер.)<br>РЗп - расланган план (рейд) биремнәре саны (бер.) | | (караулар) |
| 1.2. | Планнан тыш тикшерүләр үтәлеше | Ввн = (Рф / Рп) x 100 | Ввн - планнан тыш тикшерүләр үткәрү<br>Рф - планнан тыш үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.)<br>Рп - планнан тыш тикшерүләр үткәрүгә күрсәтмәләр саны (бер.) | 100 % | Контроль органына кергән хатлар һәм шикаятьләр |
| 1.3. | Нәтиҗәләренә шикаятьләр бирелгән тикшерүләр өлеше | x 100 / Пф | Ж - шикаятьләр саны (бер).<br>Пф - үткәрелгән тикшерүләр саны | 0% | |
| 1.4. | Нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган тикшерүләр өлеше | Пн x 100 / Пф | Пн - дөрес түгел дип табылган тикшерүләр саны (бер.)<br>Пф - үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) | 0% | |
| 1.5. | Милекче булмауга бәйле рәвештә үткәрелә алмаган | x 100 / Пф | Тикшерелә торган зат булмау сәбәпле уздырылмаган тикшерүләр | 30% | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | планнан тыш тикшерүләр өлеше һ.б. | | (бер.) Пф - үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) | | |
| 1.6. | Килешү кире кагылган планнан тыш тикшерүләр уздыру турында прокуратурага килештерүгә юнәлдерелгән гаризалар өлеше | Кзо х 100 / Кпз | Кзо - килештерүдән баш тарткан гаризалар саны (бер.) Кпз - килештерүгә бирелгән гаризалар саны | 10% | |
| 1.7. | Нәтиҗәләре буенча материаллар кабул итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрелгән тикшерүләр өлеше | Кнм 100 / Квн | К нм- вәкаләтле органнарга юнәлтелгән материаллар саны(бер.) Квн - ачыкланган бозулар саны (бер.) | 100 % | |
| 1.8. | Үткәрелгән профилактик чаралар саны | | | данә | |
| **2.** | **Кулланылыштагы хезмәт ресурслары күләмен характерлаучы хосусый күрсәткечләр** | | | | |
| 2.1. | Штат берәмлекләре саны | | | кеше | |
| 2.2. | Муниципаль контроль органы хезмәткәрләренә контроль чаралар йөкләнеше | Км / Кр= Нк | Км - контроль чаралар саны (бер.) Кр - муниципаль контроль органы хезмәткәрләре саны (бер.) Нк - 1 хезмәткәргә йөкләнеш (бер.) | | |